# Малайларга, кызларга@.RU

***Хөрмәтле укучылар, укытучылар, Лицеебыз кунаклары!***

***Сезнең алда- Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилеена багышланган махсус чыгарылыш.***



** Тарихка күз салсак...*

**1941 ел, 22 июнь. Радио шомлы хәбәр китерә. Фашистлар Германиясе Советлар иленә вәхшиләрчә һөҗүм ясый. Ватан сугышы башлана. Шул көнне үк завод-фабрикаларда, мәктәп-институтларда, колхозларда, гомумән, бөтен җирдә митинглар үткәрелә. Эшчеләр, колхозчылар, студентлар, укучылар, врачлар, барлык кеше сугышка каршы булуларын белдерәләр.**

# 1418 көн...

**Егылып калды Тарих күкләреннән
Мең дүрт йөз атылган кош...
Төзек түгел гомер чылбырлары
Күпме бәхетләрнең урыны буш !
1418 кара кояш,
Атмаган таң 1418...
1418 набат чаңы:
\- Гасырларга әйтегез, әйтегез
Бөтен түгел Тарих, төзек түгел-
Көннәр җитми 1418,
Бәхетсез сан җирдә - 13 түгел,
Билгеле ул: 1418 !...**

**(Х.Әюпов)**

## * Гаилә истәлекләре

***Гөлчәчәк Шәяхмәтова, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

*Минем картәниемнән сугыш вакытындагы тормышы турында сорасаң, ул беразга тын кала, күзләренә яшьләр килә, кәефе төшә. Шуңа күрә мин аңа ул чорны исенә төшермәскә тырышам. Ник дигәндә авыр вакыт булган ул, хәтердән чыкмаслык...Әбиемнең сөйләгәннәре әле дә истә:*

*"Ямьле җәйнең сабан туе көнендә башланды ул канлы сугыш. 1941 нче елның 22 нче июнь иртәсе иде.Кояшлы матур иртә... Арышлар инде буйга җитеп килә. Озакламый аларны җыеп алырга вакыт җитә. Кырларда күп көч таләп итә торган чор.Әмма сугыш үзенекен алды. 18 яшьтән алып барлык ир- атларны фронтка, илебезне саклар өчен алып киттеләр. Менә шунда башланды да инде барлык авырлыклар.*

*Бу тетрәндергеч хәл Авыргазылыларны да читтә калдырмады. Хатын – кызлар һәм яшүсмерләр җәфаланып игеннәрне урдылар, ир-атлар урынына тракторларга утырдылар. Көнне төнгә ялгап басуга чыгып бодай бөртекләренә кадәр җыйдылар. Кыр эшләреннән бушаган арада мал карап, оекбашлар бәйләп, фронтка җибәрделәр.*

*Фронттан котычкыч хатлар килә торды. Арасында үлү хәбәрләре дә бар.Әмма халык нык , тырыш булды."*

*Минем карт бабам да Афыргазы районы Иске Ибрай авылыннан . Аның иеме Әбделгани булган.Ул 1916 нче елгы. Фронтка кеше җитмәү сәбәпле, бабамны 1941 нче елда фронтка алып китәләр.1944 нче елның көзендә бабамның каты яралануы турында хәбәр килә. Соңгы хаты да шул елны килә...*

*Сугыш чорында атнаның һәр шимбә көнендә Авыргазыдагы "Кызыл Башкирия" колгозы председателе җыелыш уздыра торган булган. Анда ул колхоз эшләреннән башка, халыкны фронт хәбәрләре белән дә таныштырган. Халыкка шунысын да аңлатткан: әгәр дә Гитлер самолетлары бәзнең тирәдән очса, тәрәзәләрдәге утлар күренмәсен өчен, пыяласына кара ленталар ябыштырырга кушкан.*

*Сугыш чорындагы тыл тормышы бик авыр булган. Ул авырлыкны хәзерге буын татымасын иде, чөнки сугыш ул- ачы күз яшьләре, үлем, хәсрәт һәм зур югалтулар. Андый югалтуларны минем күрәсем килми.*



## *Укучылар иҗаты

**_Ильвина Гайнуллина, 8б сыйныф укучысы_**

*Бөек Ватан сугышының тынганына 70 ел вакыт үтте. Мин үзем дә, әти-әнием дә сугыш чорын күрмәдек. Бу канкойгыч сугыш турында ишетеп кенә беләбез. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Япь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я әтиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Ачлыктан тилмереп үлүчеләр дә күп була сугыш елларында. Шулай ук фашист концлагерьларында һәлак булучыларның саны да исәпсез. Бу сугышта бик күп якташларыбыз корбан булган. Нинди зур югалтулар!*

*Ләкин халыкның тырышлыгы бушка китми: күптән көтелгән Җиңү көне килә. Бу көн халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас көн булып уелып кала. Хәзерге вакытта да 9 нчы Май Җиңү көне буларак билгеләп үтелә.*

*Тик шулай да, күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.*

*Без ел саен 9 нчы Май көнендә Бөек Җиңүгә багышланган бәйрәм парадын карарга барабыз. Анда күкрәкләренә орден-медальләр таккан чал чәчле ветераннарны күргәч, безгә тыныч тормыш бүләк иткән өчен рәхмәт хисе уяна. Чал чәчләреннән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә аларга!*

### Онытмабыз!

**_Җиңү көнендә бергәләп_**
**_Без һәйкәлгә барабыз_**
**_Батырларны искә алып_**
**_Кызыл гөлләр салабыз._**

**_Арысландай сугышып,_**
**_Безнең өчен тырышып,_**
**_Башларын салган алар,_**
**_Еракта калган алар._**

**_Онытмыйча без саклыйк_**
**_Өлкәннәрнең киңәшен._**
**_Истә чакта кадерлик,_**
**_Алар кайгы белмәсен!_**

## *Өчпочмаклы салдат хатлары...

*Хатлар, хатлар...Өчпочмаклы, ак, зәңгәр яки ал конвертлы, читенә кыр почтасының тәртип саны куелган, штемпель сугылган хатлар. Әллә ничә төрле кулъязма...төрле төстәге карандашлар, төрле төстәге кара белән язылган алар. Төрле-төрле телдәге бу хатларда бер максат, бер уй, бер теләк бик ачык чагыла: җиңүгә ышаныч!*

*Солдат хатлары... Күз алдыгызга китерегез:кыска гына ял вакытында солдат окопта яки блиндажда, кәгазен калай төбенә яки тез башына куеп, хат яза. Бу кечкенә генә кәгазьдә дошманны чигендереп алган шәһәрләр һәм авыллар турында да сөйләнә. Солдат язылып беткән хатын бик пөхтәләп, өчпочмаклап төрә, адресын яза һәм кыр почтасына илтеп сала. Шулай ул, иң изге теләкләрен әйтеп, гаиләсенә сәлам хаты җибәрә.*

*Солдатлар ут эчендә. Кайберләре, искиткеч батырлык күрсәтеп, сугыштан исән чыга, ә кайберләре, дошман белән соңгы сулышына кадәр көрәшә. Ә хат, канатлы кош кебек, ерак-еракка “ оча”. Ул фронтчының ялкынлы сүзләрен туган иленә, гаиләсенә, якын кешесенә җиткерә.*

*Ә бу вакытта тылдагылар якыннарының исәнлек хатын түземсезлек белән көтеп торган. Андый хатлар килү чиксез зур бәхет, шатлык булган. Хатны, укыгач, саклык белән генә төреп, югалмаслык җиргә куйганнар, һәм аларның кайберләре безнең көннәргә кадәр сакланган. Бүген без, инде саргаеп беткән бу хатларны укып, авыр сугыш елларын искә төшерәбез. Менә шуларның берсе.*

*“ Сагынычлы сәлам хаты.Мәгълүм итүче Трофим улыгыздан әниемә һәм әтиемә,җәмәгатем Фатыймага, Минзифага, Роберт һәм Марсель улларыма бик күп сәлам. Мин бүгенгә кадәр исән-сау, аллага шөкер. Шул машинамда йөрим. Ну, туганнар, алдагысын алла гына белә... Үзегезнең хәлләрегез ничек, шуны беләсем килә. Күптәннән хатыгызны алган юк, барыгыз да исән-саулармы? Ни хәлләрегез бар, барысын да әйтеп хат сала күрегез. Минем адрес шул ук. Утыннарыгыз бармы? Балалар ач йөрмиме? Бик кайгырам сезнең өчен, туганнар. Мин ерак илләрдә хәзер, гел сугыш эчендә, бик хәтәр җирләрдә йөрибез, аллага тапшырдым, бик изге теләкләрдә торыгыз, туганнарым. Хуш, сау булыгыз. Минем адрес: 2нче Белоруссия фронты, воинская часть-50436. Бу хатны 1943 елның14 нче февралендә яздым*

*... Күп калмады инде, әнкәй, синең*
*Сагыш белән көтәр айларың.*
*Көт, кайтырбыз, Берлин өсләренә*
*Эләрбез дә җиңү байрагын...*



*Без бәхетле чорда яшибез, якты мәктәпләрдә укыйбыз, белем алабыз, үзебез яраткан эш белән шөгыльләнәбез. Җир йөзендә сугышлар кабатланмасын, алга таба да тыныч, мул, матур тормышта яшәргә язсын иде безгә!*

## *Бөек җиңү безнең хәтердә

*Кирәкми безгә кан кою,*
*Кирәкми безгә сугыш!*
*Безнең теләк якты, матур,*
*Тыныч хезмәт һәм тормыш.*
*Әхмәт Исхак*

*Халыкта “Үз язмышың үз кулыңда ” дигән әйтем бар. Әйе, күп очракта бу шулай. Үз язмышыңны үзең төзисең, ләкин шул ук вакытта якыннарың, дусларың, җәмгыять синең язмышыңа тәэсир итә. Язмышны бөтенләй башка якка үзгәрткән зур тарихи вакыйгалар да булырга мөмкин. Безнең ил тарихында шундый зур фаҗигаләрнең берсе Бөек Ватан сугышы.*

*1941 елның тыныч җәйге иртәсе. Әле яшь балалар матур төшләр күреп йоклаган чакта, офыктан яктылык күренеп китә һәм каты гөрелтәгән тавыш ишетелә. Безнең туган җиребез өстендә фашистлар бомбасының беренче кат шартлавы иде ул. Шул көннән Бөек Ватан сугышы башлана. Сугышның ачы хәсрәте бер генә гаиләгә дә кагылмый узмаган. Бабайлар, әтиләр, егетләр туган илләрен дошманнан сакларга дип изге көрәшкә күтәрелгәннәр.*

*Сугыш хәсрәте безнең гаиләгә дә килеп сарылган. Минем карт бабаем сөйләгәннәрне дәү әнием хәзердә елый-елый искә ала. Бабай сугышта күргәннәрен фашистларга нәфрәт уты белән яна-яна, ачынып-ачынып сөйли торган булган. “Без теләмәсәк тә үтерергә тиеш идек. Югыйсә, безнең үзебезне үтерәчәкләр иде... Чолганышта калгач, бөтен яктан да аталар. Кая үзебезнекеләр, кая фашистлар икәнен дә белеп булмый. Бик күп югалтулар кичереп, чолганыштан чыккач, Бөек Җиңү көне җитсен дип, гомеребезне дә кызганмыйча сугыштык.” Яшәргә, тырышырга, фашизмны җиңәргә кирәк! Җиңү киләчәгенә өмет, сугышның кырыс юлларын үтеп чыгарга ярдәм иткән. Ләкин бабам бик каты яралана һәм бу озак көтелгән Җиңү көнен госпитальдә каршылый. Исән-сау үзенең туган ягына әйләнеп кайта.*

*9 май илебезгә шатлык алып килгән көн. Һәр кешенең йөзендә елмаю, күзләрендә яшь булган. Бу яшьләр-шатлык һәм кайгы яшьләре. Кайгы яшьләре, чөнки миллионлаган кеше бу сугышта һәлак булган, якыннарын югалткан. Шатлык яшьләре, чөнки бу бит яшәргә тырышып-тырмашып, озак көттереп килгән Җиңү көне. Быел без Җинүнең 70еллыгын билгеләп үтәбез.*

*Кешелек дөньясы сугышлардан ачы сабак алып, җир йөзендә мәңге тынычлык, бәхет өчен көрәшергә тиеш. Сугышлар беркайчанда булмасын иде. Бомба утлары иген-кырларны, урманнарны шәһәрләрне, мәктәпләрне яндырмасын! Безгә тынычлык кирәк!*

***Регина Акбашева, 5в сыйныф укучысы***

## *Җәлилчеләр батырлыгы үлемсез...

**Җәлилчеләр** - Икенче Бөтендөнья сугышы вакытындаБерлиндагы Плетцензее төрмәсендә һәлак булган Муса Җәлил һәм аның ун көрәштәше.

1944нче елның 25 нче августында җәлилчеләрне соңгы юлга – палач балтасы астына алып баралар. Конвоирларның котын алып, төрмә камераларында газап чигүче тоткыннарның күңелендә яшәүгә өмет уятып, үлем аша үлемсезлеккә илтүче 114 адымны (камерадан гильотинога кадәр шул чаклы адым) җырлап үткәннәр, башлары киселгәндә дә елмаеп үләләр!

**Җәлилчеләр исемлеге**

| Исеме | Үлем сәгате | Туган ягы |
|---|---|---|
| Гайнан Кормаш | 12 сәгать 06 минут | Актүбә, Казакъстан |
| Фоат Сәйфелмөлеков | 12 сәгать 09 минут | Ташкент, Үзбәкстан |
| Абдулла Алиш | 12 сәгать 12 минут | Көек, Татарстан |
| Фоат Булатов | 12 сәгать 15 минут | Мәләвез, Башкортстан |
| Муса Җәлил | 12 сәгать 18 минут | Мостафа, Ырымбур өлкәсе |
| Гариф Шабаев | 12 сәгать 21 минут | Иске Турай, Башкортстан |
| Әхмәт Симаев | 12 сәгать 24 минут | Усть-Рахмановка, Пенза өлкәсе |
| Абдулла Баттал | 12 сәгать 27 минут | Зур Тигәнәле, Татарстан |
| Зиннәт Хәсәнов | 12 сәгать 30 минут | Иске Кәшер, Татарстан |
| Әхәт Атнашев | 12 сәгать 33 минут | Петропавловск, Казакъстан |
| Сәлим Бохаров | 12 сәгать 36 минут | Миякә, Башкортстан |



***Ветераннар, данлы ветераннар,***
***Сирәгәя бара сафлары.***
***Өзгәләнеп искә алалар***
***Көрәшләрдә узган чакларны.***

